
«Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия – интернат»
дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе

# *Тема: Роберт Миңнуллин иҗатында туган як образы.*

***Башкаручы: Шәрифуллина Алия Вил кызы (тәрбияче)***


***Эшемнең максаты: Роберт Миңнуллин иҗатында туган җир, туган як темасына кагылышлы әсәрләрен өйрәнү.***



Балалар шагыйре Роберт Миңнуллин иҗатының буеннан-буена сузылып килгән ике образына сокланам: аның берсе ана образы булса, икенчесе- туган як образы. Туган як һәм иң кадерле кеше-ана турында шигырь язмаган шагыйрьне табу мөмкин түгелдер. Шулай да Роберт Миңнуллин – бу темаларга иң күп һәм иң җимешле язучы шагыйрьләребезнең берсе. Авторның йөрәгеннән чыккан ихлас сүзе,әлбәттә, укучы йөрәгенә дә барып җитә, анда җавап хисе, җылы тойгылар уята.



# Әйдә безгә - Сөн буена.




*Исәнмесез,Чагыл, Хан таулары!*
*Исәнмесез ,Сөнем, авылым!*
*Гомеремне күргән кебек булам,*
*Күрсәм әгәр Сөннең агымын.*

*Исәнмесез кайтыр юлларым!*
*Исәнмесез,тап — тар сукмакларым!*
*Юлларыма үземнән дә алда*
*Килеп чыга яңа җырларым.*

***Роберт ага Миңнуллин туган авылы Шәммәттә***





Менә шундый инде минем
Туган җирем, Туган ягым.

Мин төзәлә алмам, ахры,-
Мактанылды менә тагын!



Әйе, шагыйрьнең Туган ягы – әкияттәгедәй гүзәл сурәтләргә әйләнеп, шигырьләренә һәм җырларына күчкән образ. Язын кошлар үз ояларына әйләнеп кайткан кебек шагыйрь җаны, аның канатлы хыялы шул Сөненә әйләнә дә кайта. Роберт Миңнуллин бертуктаусыз язып тора, язган саен яңара, матурлана бара аның туган ягы да. Ул лирик җанлы, романтик рухлы, фәлсәфи карашлы, гражданин хисле әдип. Ул – бөтен җаны-тәне белән авыл шагыйре, яшьлек, туган якны зурлап җырлаучы.

# Нәтиҗәсе

Шагыйрь туган як образы аша балаларны туган якны яратырга чакыра. Акыллы , тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди.



Җирне без дә яратабыз,
Ватан газиз безгә дә...
Зәңгәр күк – безнең Сөю ул,
Безнең Сөю ул – ал таң...
Кемнең ничек яратканын
Үзе белә ул Ватан!

# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!